Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының сиксән беренче утырышы

Богородский авыл җирлеге Советы карары

2019 ел, 6 май № 148

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының карары 2017 елның 14 декабрендәге 95 номеры белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, 2019 елның 29 апрелендәге халык тыңлаулары нәтиҗәсе белән, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 декабрендәге 95 номерлы карары белән расланган Богородский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба текст буенча – Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлектә «Алар урнашкан биналар, корылмалар һәм җир кишәрлекләре, фасадларның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтенә, юллар, индивидуаль торак йортлар, яңгыр канализациясе челтәрләре, күзәтү һәм яңгыр коесы, су бирү корылмалары, техник элемтә чаралары, тышкы яктырту объектлары, кече архитектура формалары, стационар булмаган объектлар, төзелеш эшләре урыннары, җирләү урыннары, автотранспорт чараларының озак вакытлы һәм кыска вакытлы сакланышына карата таләпләр. Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү»:

- «йорт билгеләре» 3.3 пунктын киләсе эчтәлектге 3.3.3. пунктчасы белән тулыландырырга:

3.3.3. Йорт билгеләренә, тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү белән урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш булырга тиеш, дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән. Элмә такталарында булган һәр мәгълүмат кулланучыларга ике дәүләт телендә, ягъни рус һәм татар телләрендә житкерелергә тиеш.»;

- «Җир кишәрлекләрен карап тоту» 3.6 пунктын киләсе эчтәлектәге 3.6.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.6.2. Үсемлекләрне зонтиклылардан, шул исәптән Нарат борщевигыннан (алга таба - борщевик) арындыру буенча чаралар үткәрү.

Борщевканы бетерү буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелә ала:

гербицидлар һәм (яки) арборицидлар белән үсү учакларын химик-сиптерү;

механик-чаптыру, коры үсемлекләрне җыю, тамыр системасын казып алу;

агротехник-туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәрне чәчү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Ф.Д. Фәезов